Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Кече Талкыш авыл җирлеге Советы
карары

09.06.2023 ел №32/3

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Кече Талкыш авыл җирлеге Советының 2020 елның 18 июнендәге 80/3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Чистай муниципаль районының Кече Талкыш авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Кече Талкыш авыл җирлеге Советының 2020 елның 18 июнендәге «Татарстан Республикасы “Кече Талкыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат биргән өчен, әгәр дә бу мәгълүматларны бозып бирү әһәмиятсез булса, җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү Тәртибе турында”гы 80/3 номерлы карары белән расланган мөлкәт характерындагы йөкләмәләр, шулай ук керемнәр, чыгымнар турында, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, әгәр бу мәгълүматларны бозу әһәмиятсез булса Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Кече Талкыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирле үзидарәсе депутатына, сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен җаваплылык чараларын күрү Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3 пунктның икенче абзацында, 4 пунктта, 5 пунктның икенче абзацында, 6 пунктның беренче абзацында, 7 пунктның беренче һәм өченче абзацларында "Татарстан Республикасы Президенты" сүзләрен “Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)" сүзләре белән алыштырырга;

11 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президентына» дигән сүзләрне «Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә)» дигән сүзләр белән алыштырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләрнең күпләп җыелган урыннарда, игълан итү стендларында һәм такталарында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Keче Талкыш авыл
җирлеге башлыгы Г.Н.Федотов